# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы закон актлары аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 16 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында" 1992 елның 8 июлендәге 1560-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына (2004 елның 28 июлендәге 44-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 6; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1996, № 4;  2004, № 7 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) беренче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасындагы башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан  эшләнә, раслана һәм гамәлгә ашырыла.";

2) бишенче өлешне үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

"Янгын куркынычсызлыгы турында" 1993 елның 18 маендагы 1866-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы алтынчы

абзацына (2005 елның 26 февралендәге 54-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 11 – 12; 1994, № 1 – 2; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1996, № 2, № 11; 1999, № 3; 2001, № 3; 2002, № 12 (II өлеш); 2005, № 2; 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 4; 2008, № 6; 2011, № 5), түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

"янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә республика максатчан программаларын эшләү, раслау һәм гамәлгә ашыру;".

**3 статья**

"Мәдәният турында" 1998 елның 3 июлендәге 1705 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 7; 2000, № 12 (11) (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 7 – 8 (I өлеш); 2011, № 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 15 статьяның икенче абзацында "мәдәният өлкәсендә", "һәм иң мөһим республика дәүләт программаларын раслау" сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 16 статьяның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"мәдәният өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру, республика максатчан программаларын эшләү, раслау һәм гамәлгә ашыру;".

**4 статья**

Татарстан Республикасы Җир кодексына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 1999, № 8 (I өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12, (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; Ватаным Татарстан, 2011, 23 ноябрь) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 2 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

2) 3 статьяның 2 пунктчасында "Татарстан Республикасы программаларын эшләү һәм гамәлгә ашыру" сүзләрен "республика максатчан программаларын эшләү, раслау һәм гамәлгә ашыру" сүзләренә алмаштырырга.

**5 статья**

"Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында" 2004 елның 8 декабрендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш); 2006, № 7

(I өлеш); 2007, № 11; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 5) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8 статьяның өченче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

2) 9 статьяның беренче өлешенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
"халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә республика максатчан программаларын эшләү, раслау һәм гамәлгә ашыру.".

**6 статья**

"Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында" 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 4 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяның 3 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

2) 6 статьяга түбәндәге эчтәлекле $3^1$ пунктча өстәргә:
"$3^1$) мәдәни мирас объектларын дәүләт саклавы, саклап тоту, куллану һәм популярлаштыру өлкәсендә республика максатчан программаларын эшләү, раслау һәм гамәлгә ашыру;".

**7 статья**

"Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару хезмәтләре һәм һәлакәттән коткару формированиеләре турында" 2005 елның 29 декабрендәге 134-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы өченче абзацын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 12 (IV өлеш); 2008, № 10 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш) үз көчен югалткан дип танырга.

**8 статья**

"Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында" 2006 елның 20 июнендәге 42-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 6 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның дүртенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

2) 3 статьяның өченче абзацында "эшләү" сүзеннән соң ", раслау" сүзен өстәргә.

**9 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2012 елның 3 марты
№ 16-ТРЗ